# КАРАР

2022 елның 26 ноябре № 1

**Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Кече Чура авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәсе турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 22 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районының Югары-Чура авыл җирлеге Кече Чура авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә срокглы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; шулай ук Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 700 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Кече Чура авылының Яшел, Мәктәп урамнарындагы юлларга вак таш җәю (вак таш сатып алу, ташу, җәю); проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;
- Кече Чура авылы Мәктәп, Тукеев Федот урамнарына вак таш җәеп, юлларда чокырларны ремонтлау; проект-смета документларны эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;
- Кече Чура авылында урамнарны яктырту өчен энергия саклаучы лампалар сатып алу, урнаштыру, яктырткычларны, махсус җиһазларны ремонтлау; килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;
- Кече Чура авылының Мәктәп урамына юл билгеләре сатып алу; килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;
- Кече Чура авылында Бәр елгасы җәяүлеләр чыгу юлын ремонтлау; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;
- Кече Чура авылы зиратын коймалау өчен материал сатып алу; килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;
- Кече Чура авылының урам юл челтәрен карап тоту (юлларны кардан чистарту һәм территорияне җәй көне чабу; ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Кече Чура авылындагы балалар һәм спорт уен мәйданчыкларын карап тоту (килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- Кече Чура авылы урамнарында коры агачларны һәм куакларны кисеп ташлау, кисү, төпләү һәм санитар эшкәртү; махсус техника яллау; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;
- Кече Чура авылына видеокамералар сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;

- Кече Чура авылының Яшел урамына асфальт җәю һәм вак таш җәеп ремонтлау; проект-смета документларын эшләү һәм экспертиза, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 181 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 98.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашкан 98 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлеге Кече Чура авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районының Югары-Чура авыл җирлеге Кече Чура авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; шулай ук Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 700 сум күләмендә үзара салым кертүне һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүне расларга карар иттек:

- Кече Чура авылы Яр буе, Яшел урамнары, Яшел урам тыкрыгы юлларына вак таш җәю; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Кече Чура авылы Мәктәп, Яшел, Тукеев Федот урамнарына вак таш җәеп, юлларда чокырларны ремонтлау; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Кече Чура авылына урам яктырту лампалары сатып алу, урнаштыру, яктырткычларны, махсус җиһазларны ремонтлау;
- Кече Чура авылы Мәктәп урамына юл билгеләре сатып алу һәм урнаштыру;
- Кече Чура авылында Бәр елгасы җәяүлеләр чыгу юлын ремонтлау; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Кече Чура авылында зиратны карап тоту, зиратны коймалау өчен материал сатып алу;
- Кече Чура авылының урам юл челтәрен карап тоту, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, тракторчы-машинист хезмәте күрсәтү;
- Кече Чура авылында балалар һәм спорт уен мәйданчыкларын, ял итү зоналарын карап тоту һәм төзекләндерү;
- Кече Чура авылы урамнарында коры агачларны һәм куакларны кисеп ташлау, кисү, төпләү һәм санитар эшкәртү; махсус техника яллау; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Кече Чура авылына видеокамералар сатып алу һәм урнаштыру, видеокүзәтү системаларын урнаштыру; видеокамераларны һәм видеокүзәтү системаларын ремонтлау һәм карап тоту;
- Кече Чура авылында юлларга асфальт салу һәм вак таш җәеп ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм экспертиза, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Кече Чура авылын су белән тәэмин итү системаларын ремонтлау, карап тоту һәм реконструкцияләү;

-Кече Чура авылы балалар һәм спорт мәйданчыкларын һәм якын-тирә территорияләрне яктырту; проект-смета документларын эшләү һәм экспертиза, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру.

«РИЗА» «КАРШЫ»

- кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Югары-Чура авыл җирлеге башлыгы: В.Н. Андреев